**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Об Электронной доске почета Республики Татарстан**

В целях общественного признания профессиональных достижений и добросовестного труда граждан, их вклада в социально-экономическое развитие Республики Татарстан **постановляю**:

1. Учредить Электронную доску почета Республики Татарстан.

2. Утвердить прилагаемое Положение об Электронной доске почета Республики Татарстан.

3. Кабинету Министров Республики Татарстан:

обеспечить создание и функционирование Электронной доски почета Республики Татарстан;

обеспечить финансирование расходов, связанных с исполнением настоящего Указа, а также принять иные решения, необходимые для его реализации.

4. Предложить руководителям организаций, независимо от их организационно-правовой формы и формы собственности, индивидуальным предпринимателям, которые осуществляют свою деятельность на территории Республики Татарстан (далее – организации), руководителям государственных органов Республики Татарстан, территориальных органов федеральных государственных органов по Республике Татарстан, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан ежегодно в установленном порядке осуществлять выдвижение кандидатов для занесения на Электронную доску почета Республики Татарстан.

5. Республиканским органам исполнительной власти оказать содействие организациям в курируемой сфере деятельности (отрасли экономики) по вопросам выдвижения кандидатов для занесения на Электронную доску почета Республики Татарстан.

6. Рекомендовать главам муниципальных районов и городских округов Республики Татарстан организовать работу по оказанию содействия организациям, осуществляющим деятельность на территории соответствующего муниципального района, городского округа Республики

Татарстан, по вопросам выдвижения кандидатов для занесения на Электронную доску почета Республики Татарстан.

7. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ

Казань, Кремль
01 мая 2026 года
№ 356

Утверждено
Указом Раиса
Республики Татарстан

от « 01 » мая 2026 года

№ 356

# ПОЛОЖЕНИЕ
## об Электронной доске почета Республики Татарстан

1. Настоящее Положение определяет правовой статус Электронной доски почета Республики Татарстан (далее – Доска почета Республики Татарстан), порядок выдвижения и занесения на Доску почета Республики Татарстан граждан Российской Федерации, осуществляющих трудовую деятельность на территории Республики Татарстан (далее – работники).

2. Доска почета Республики Татарстан является нематериальной формой поощрения работников за высокие профессиональные достижения, добросовестный труд, личный вклад в государственное и социально-экономическое развитие Республики Татарстан и иные заслуги перед Республикой Татарстан.

3. Занесение на Доску почета Республики Татарстан служит признанием заслуг работника и осуществляется ежегодно по результатам профессиональной деятельности за год, предшествующий году формирования Доски почета Республики Татарстан.

4. Доска почета Республики Татарстан создается и функционирует в электронной форме в виде сайта «Электронная доска почета Республики Татарстан» в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» по адресу: www.gordost.tatar.ru (далее – сайт).

5. Занесение работников на Доску почета Республики Татарстан осуществляется сроком на один год.

6. Право на выдвижение работников для занесения на Доску почета Республики Татарстан имеют организации, независимо от их организационно-правовой формы и формы собственности, индивидуальные предприниматели, которые осуществляют свою деятельность на территории Республики Татарстан (далее – организации), государственные органы Республики Татарстан, территориальные органы федеральных государственных органов по Республике Татарстан, органы местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан (далее – органы).

7. Выдвижение кандидатов для занесения на Доску почета Республики Татарстан осуществляется из числа работников, имеющих стаж работы (службы) в сфере деятельности органа или организации не менее трех лет и не имеющих на день выдвижения для занесения на Доску почета Республики

Татарстан дисциплинарных взысканий, при их соответствии не менее чем одному из следующих условий:

наличие высоких результатов в сфере деятельности (отрасли экономики), перевыполнение плановых показателей, внедрение новых технологий, рационализаторских предложений, которые повысили эффективность работы органа или организации;

наличие конкретных профессиональных заслуг, участие в значимых проектах, осуществление наставнической деятельности;

общественная активность работника, участие в благотворительных проектах, волонтерской деятельности, патриотическом воспитании подрастающего поколения;

награждение государственными наградами Российской Федерации, наградами Президента Российской Федерации, правительственными наградами Российской Федерации, ведомственными наградами Российской Федерации, государственными наградами Республики Татарстан, Благодарностью Раиса Республики Татарстан, поощрением Государственного Совета Республики Татарстан, Благодарностью Кабинета Министров Республики Татарстан, ведомственными наградами Республики Татарстан, муниципальными наградами;

признание лауреатом государственной премии Российской Федерации или государственной премии Республики Татарстан;

занятие призовых мест по результатам участия во всероссийских конкурсах профессионального мастерства в году, предшествующем формированию Доски почета Республики Татарстан.

8. Определение кандидата для занесения на Доску почета Республики Татарстан осуществляется руководителем органа или организации по результатам отборочных процедур, устанавливаемых соответствующим органом или организацией.

Отбор проводится в период с 11 мая по 11 июня года, в котором осуществляется формирование Доски почета Республики Татарстан.

9. Кандидатуры работников организаций для занесения на Доску почета Республики Татарстан после отбора размещаются в период с 12 по 20 июня года, в котором осуществляется формирование Доски почета Республики Татарстан, в закрытом контуре сайта для рассмотрения исполнительным комитетом соответствующего муниципального района, городского округа Республики Татарстан.

10. Руководитель исполнительного комитета муниципального района, городского округа Республики Татарстан в период с 21 июня по 31 июля года, в котором осуществляется формирование Доски почета Республики Татарстан, принимает решение о согласовании занесения кандидатуры работника на Доску почета Республики Татарстан при соответствии работника условиям, предусмотренным пунктом 7 настоящего Положения.

При отсутствии согласования занесение работника на Доску почета Республики Татарстан не осуществляется.

11. Размещение информации о работниках для занесения на Доску почета Республики Татарстан осуществляется через личный кабинет органа или организации на сайте в период с 1 по 20 августа года, в котором осуществляется формирование Доски почета Республики Татарстан.

Размещение информации о работниках на Доске почета Республики Татарстан осуществляет руководитель органа или организации, заместитель руководителя по кадрам или иное должностное лицо, ответственное за кадровую работу в органе или организации.

Руководитель органа или организации обеспечивает достоверность информации о работниках, размещаемой на Доске почета Республики Татарстан.

12. На Доске почета Республики Татарстан размещаются фотопортреты работников с указанием их фамилий и инициалов в соответствии с требованиями, установленными Федеральным законом от 27 июля 2006 года № 152-ФЗ «О персональных данных».

13. Занесение на Доску почета Республики Татарстан подтверждается свидетельством. Форма свидетельства утверждается Кабинетом Министров Республики Татарстан.

14. Свидетельство вручается работнику лицом, замещающим государственную должность Республики Татарстан, муниципальную должность, руководителем (заместителем руководителя) органа или организации.

15. Повторное выдвижение работника для занесения на Доску почета Республики Татарстан возможно не ранее чем через пять лет после предыдущего выдвижения.

16. Организационно-методическое обеспечение функционирования Доски почета Республики Татарстан осуществляется Министерством труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан. Организационно-техническое обеспечение функционирования Доски почета Республики Татарстан осуществляется Министерством цифрового развития государственного управления, информационных технологий и связи Республики Татарстан.

---

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының электрон мактау тактасы турында**

Җәмгыятьтә гражданнарның һөнәри казанышларын һәм намуслы хезмәтләрен, Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлешен тану максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының электрон мактау тактасын гамәлгә куярга.

2. Кушымтада бирелә торган Татарстан Республикасының электрон мактау тактасы турында нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:
Татарстан Республикасының электрон мактау тактасын булдыруны һәм аның гамәлен тәэмин итәргә;
әлеге Указны үтәү белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә, шулай ук аны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка карарлар кабул итәргә.

4. Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара торган төрле оештыру-хокукый рәвешендәге һәм милекчелек рәвешендәге оешмалар җитәкчеләренә, шәхси эшкуарларга (алга таба – оешмалар), Татарстан Республикасы дәүләт органнары, федераль дәүләт органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә билгеләнгән тәртиптә ел саен Татарстан Республикасының электрон мактау тактасына кертү өчен кандидатлар күрсәтүне тәкъдим итәргә.

5. Республика башкарма хакимияте органнарына үзләре күзәтчелек иткән эшчәнлек өлкәсендә (икътисад тармагында) оешмаларга Татарстан Республикасының электрон мактау тактасына кертү өчен кандидатлар күрсәтү мәсьәләләре буенча ярдәм күрсәтергә.

6. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына Татарстан Республикасының тиешле муниципаль

районы, шәһәр округы территориясендә эшчәнлек алып бара торган оешмаларга Татарстан Республикасының электрон мактау тактасына кертү өчен кандидатлар күрсәтү мәсьәләләре буенча булышлык итү эшен оештыруны тәкъдим итәргә.

7. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 01 май
№ 356

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның «_01_» _маендагы_
_356_ номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасының электрон мактау тактасы турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасының электрон мактау тактасының (алга таба – Татарстан Республикасының мактау тактасы) хокукый статусы, Татарстан Республикасы территориясендә хезмәт эшчәнлеге алып баручы Россия Федерациясе гражданнарын (алга таба – хезмәткәрләр) Татарстан Республикасының мактау тактасына тәкъдим итү һәм кертү тәртибе билгеләнә.

2. Татарстан Республикасының мактау тактасы – югары һөнәри казанышлары, намуслы хезмәтләре, Татарстан Республикасының дәүләти һәм социаль-икътисадый үсешенә шәхси өлеш кертүләре һәм Татарстан Республикасы алдындагы башка казанышлары өчен хезмәткәрләрне матди булмаган бүләкләү рәвеше.

3. Татарстан Республикасының мактау тактасына кертелүе хезмәткәрнең казанышларын тану булып тора һәм Татарстан Республикасының мактау тактасы формалаштырылган ел алдыннан килә торган елдагы һөнәри эшчәнлек йомгаклары буенча һәр ел саен гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасының мактау тактасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге www.gordost.tatar.ru адресында «Татарстан Республикасының электрон мактау тактасы» сайты (алга таба – сайт) рәвешендә электрон формада булдырыла һәм гамәлдә була.

5. Хезмәткәрләр Татарстан Республикасының мактау тактасына бер елга кертелә.

6. Хезмәткәрләрне Татарстан Республикасының мактау тактасына кертү өчен тәкъдим итү хокукына Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара торган төрле оештыру-хокукый рәвешендәге һәм милекчелек рәвешендәге оешмалар, шәхси эшкуарлар (алга таба – оешмалар), Татарстан Республикасы дәүләт органнары, федераль дәүләт органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары (алга таба – органнар) ия.

7. Татарстан Республикасының мактау тактасына кертү өчен кандидатлар орган яисә оешма эшчәнлеге өлкәсендә кимендә өч ел эш

(хезмәт) стажы булган һәм Татарстан Республикасының мактау тактасына кертү өчен тәкъдим ителгән көнгә дисциплинар җәза бирелмәгән хезмәткәрләр арасыннан, алар түбәндәге шартларның ким дигәндә берсенә туры килгән очракта сайлап алына:

эшчәнлеге өлкәсендә (икътисад тармагында) югары нәтиҗәләргә ирешүе, план күрсәткечләрен арттырып үтәве, орган яисә оешманың эшчәнлеге нәтиҗәлелеген күтәргән яңа технологияләрне, рационализаторлык тәкъдимнәрен кулланышка кертүе;

тәгаен һөнәри казанышлары булуы, әһәмиятле проектларда катнашуы, остазлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруы;

хезмәткәрнең иҗтимагый активлыгы, хәйрия проектларында, волонтерлык эшчәнлегендә, яшь буынга патриотик тәрбия бирүдә катнашуы;

Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре, Россия Федерациясе Президенты бүләкләре, Россия Федерациясенең хөкүмәт бүләкләре, Россия Федерациясенең ведомство бүләкләре, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре, Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы бүләге, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Рәхмәте, Татарстан Республикасының ведомство бүләкләре, муниципаль бүләкләр белән бүләкләнгән булуы;

Россия Федерациясе дәүләт премиясе лауреаты яисә Татарстан Республикасы дәүләт премиясе лауреаты дип танылуы;

Татарстан Республикасының мактау тактасы формалаштырыла торган ел алдыннан килә торган елдагы бөтенроссия һөнәри осталык конкурсларында катнашу йомгаклары буенча призлы урыннар яулавы.

8. Татарстан Республикасының мактау тактасына кертү өчен кандидатны орган яисә оешма җитәкчесе тиешле органнар һәм оешмалар урнаштыра торган сайлап алу процедуралары йомгаклары буенча билгели.

Сайлап алу Татарстан Республикасының мактау тактасы формалаштырыла торган ел алдыннан килә торган елның 11 маеннан 11 июненә кадәрге чорда уздырыла.

9. Татарстан Республикасының мактау тактасына кертүгә оешмалар хезмәткәрләренең кандидатуралары сайлап алудан соң Татарстан Республикасының мактау тактасы формалаштырыла торган ел алдыннан килә торган елның 12 июненнән 20 июненә кадәрге чорда Татарстан Республикасының тиешле муниципаль районы, шәһәр округы башкарма комитетына карап тикшерү өчен сайтның ябык контурында урнаштырыла.

10. Татарстан Республикасының муниципаль районы, шәһәр округы башкарма комитеты җитәкчесе Татарстан Республикасының мактау тактасы формалаштырыла торган елның 21 июненнән алып 31 июленә кадәрге чорда хезмәткәр кандидатурасын, хезмәткәр әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында каралган шартларга туры килгән очракта, Татарстан Республикасының мактау тактасына кертүне килештерү турында карар кабул итә.

Килештерелмәгән очракта, хезмәткәр Татарстан Республикасының мактау тактасына кертелми.

11. Хезмәткәрләр турындагы Татарстан Республикасының электрон мактау тактасына кертү өчен мәгълүмат орган яисә оешманың сайттагы шәхси кабинеты аша Татарстан Республикасының мактау тактасы формалаштырыла торган елның 1 августыннан 20 августына кадәрге чорда урнаштырыла.

Татарстан Республикасының мактау тактасында хезмәткәрләр турында мәгълүматны орган яисә оешма җитәкчесе, җитәкченең кадрлар буенча урынбасары яисә органда яки оешмада кадрлар эше өчен җаваплы башка вазыйфаи зат урнаштыра.

Орган яисә оешма җитәкчесе хезмәткәрләр турында Татарстан Республикасының мактау тактасында урнаштырыла торган мәгълүматның дөреслеген тәэмин итә.

12. «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләр нигезендә Татарстан Республикасының мактау тактасына хезмәткәрләрнең фотосурәтләре, фамилиясе һәм инициаллары күрсәтелеп, урнаштырыла.

13. Татарстан Республикасының мактау тактасына кертелү таныклык белән раслана. Таныклыкның формасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

14. Таныклык хезмәткәргә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны биләүче зат, орган яисә оешма җитәкчесе ( җитәкче урынбасары) тарафыннан тапшырыла.

15. Хезмәткәрне Татарстан Республикасының мактау тактасына кертү өчен кабат тәкъдим итү аңа кадәрге тәкъдим ителүдән соң кимендә биш ел узгач кына мөмкин була.

16. Татарстан Республикасының мактау тактасының гамәлдә булуын оештыру-методик яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы башкара. Татарстан Республикасының мактау тактасының гамәлдә булуын оештыру-техник яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы башкара.